ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 28.08.2015 г. Казань № 5-12/тэ

“Аксубай күп тармаклы торак-коммуналь хуҗалыгы җитештерү предприятиесе” ААЖе тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифларны билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190 - ФЗ санлы Федераль законга, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәяләр хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 13 июнендәге 760-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Аксубай күп тармаклы торак-коммуналь хуҗалыгы җитештерү предприятиесе” ААЖе тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифларны әлеге карар кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән 2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча Дәүләт комитеты
карарына кушымта
28.08.2015 № 5-12/тэ

## “Аксубай күп тармаклы торак-коммуналь хуҗалыгы җитештерү предприятиесе” ААҖе тарафыннан кулланучыларга җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, җайга салу-чы оешма исеме, тариф төре | Ел | Су | Басым астында алынган пар | | | | Әче һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 дән 2,5 кг/см$^2$-га кадәр | 2,5 дән 7,0 кг/см$^2$ га кадәр | 7,0 дән 13,0 кг/см$^2$ га кадәр | 13,0 кг/см$^2$ дан артыграк | |
| | Аксубай муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | “Аксубай күп тармаклы торак-коммуналь хуҗалыгы җитештерү предприятиесе” ААҖе | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифларга дифференциация ясалмаган очракта | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум./Гкал | карар үз көченә кергән көннән 2015 елның 31 декабренә кадәр | 1725,50 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге